**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**
IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

28 февраля 2023 ел №7 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 26.05.2020 ел, № 27 карары белән расланган
Ютазы муниципаль районының депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгзасына, сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында,
хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар биргән өчен җаваплылык чаралары турындагы карарын кабул итү
Тәртибенә, әгәр бу мәгълүматларны бозу әһәмиятле булмаса, үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 25.12.2008 № 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Муниципаль вазыйфаны биләүгә, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче гражданнарның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү тәртибе хакында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Контракт буенча муниципаль вазыйфаларны биләүгә, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында»19.07.2017 ел, № 57-ТРЗ Татарстан Республикасы законы белән, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 31.12.2022 ел, № 109-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Ютазы муниципаль районы Советының 2020 елның 26 маендагы 27 номерлы карары белән расланган Ютазы муниципаль районының депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгзасына, сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар биргән өчен җаваплылык чаралары турындагы карарын кабул итү Тәртибенә, әгәр бу мәгълүматларны бозу әһәмиятле булмаса, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 3 пунктындагы 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгының - Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Тәртипнең 4 пунктында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгының - Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. Тәртипнең 5 пунктындагы 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгының - Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. Тәртипнең 6 пунктындагы 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгының - Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. Тәртипнең 7 пунктындагы 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгының - Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. Тәртипнең 7 пунктындагы 3 абзацында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгының - Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. Тәртипнең 11 пунктындагы 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына - Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгыма алам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин